СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӨНЧӘЛЕ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

улица Ленина, дом 76,
село Сунчелеево, 423052

Ленин урамы, 76 енче йорт
Сөнчәле авылы , 423052

Тел.: (84344) 4-98-24, ОГРН 1061665002080,ОКПО 94318582, ИНН/КПП 1603004776/160301001
E-mail: *Sunch.Aks@tatar.ru,* http://aksubayevo.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы**

№ 3 10 ноябрь 2025ел

«Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Сөнчәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 нче--ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының түбәндәге адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Сөнчәле авылы, Ленин урамы, 80нче йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Сөнчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы вакытта Сөнчәле авылы эчендәге юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш китерү, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү).

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт

инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарыннан файдалануны, саклауны, торгызуны оештыру тора., , җирлек торак пунктлары чикләрендә урнашкан махсус сакланылучы табигать территорияләре урманнары саклау;

- урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру).);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (торак пункт эчендәге территорияне чүп үләненнән чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (агачларны кисү)

3. Әлеге карарны Сөнчәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http:// aksubayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (httr://pravo.tatarstan.ru).

Аксубай муниципаль районы муниципаль
Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы А.В.Калуков